ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

19.12.2023

г. Казань

**КАРАР**

№ 816-63/т-2023

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезле тариф дәрәҗәсен, тарифлар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы федераль закон, «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы һәм «Тимер юл транспорты өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне дәүләти җайга салу турында» 2009 елның 5 августындагы 643 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Тимер юлда пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифлар, җыемнар һәм түләү билгеләү (үзгәртү) мәсьәләләрен карау тәртибен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен тапшырыла торган документлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 19 августындагы 506-Т номерлы боерыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Шәһәр яны билгеләнешендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өлкәсендә табигый монополия субъектлары хезмәтләренә икътисадый нигезләнгән тарифлар дәрәҗәсен формалаштырганда исәпкә алына торган икътисадый нигезләнгән чыгымнар дәрәҗәсен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2017 елның 5 декабрендәге 1649/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2023 №62-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан, әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан

пассажирлар йөртүгә икътисадый яктан нигезләнгән тариф дәрәҗәсен билгеләргә.

2. 2024 елның 1 гыйнварыннан, әлеге карарның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

3. 2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла торган шәһәр яны тимер юл транспортында Казан-Кизнер, Кизнер-Казан, Ижевск-Кизнер, Кизнер-Ижевск маршрутлары буенча уңайлылык дәрәҗәсе югары булган вагоннарда пассажирлар йөртүгә әлеге карарның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, карарның 2 нче пунктында билгеләнгән тарифларга өстәмә тарифлар билгеләргә.

4. Уңайлылык дәрәҗәсе югары булган вагонда бару бәясен түләү пассажир тарафыннан ул бара торган барча юл озынлыгына бер мәртәбә, әлеге карар кушымтасының 3 нче пунктында билгеләнгән тарифларга туры китереп түләнә.

5. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсен, тарифлар билгеләү турында» 16.12.2022 № 752-29/т-2022 карарын көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көннән дә иртәрәк түгел.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2023 № 816-63/т-2023
карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифның икътисадый нигезләнгән дәрәҗәсе

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Икътисадый яктан нигезләнгән тариф дәрәҗәсе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Тимер юл транспортында пассажирлар алып бару (дистә километрлы бер зона өчен) | 37,93 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2023 № 816-63/т-2023
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗә максималь тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1. | Алып бару аралыгына бәйсез рәвештә, сәфәр маршрутының беренче дистә чакрымыннан икенче дистә чакрымына кадәр бер пассажирны алып бару | 1 сәфәр | 36,00 |
| 2. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны өченче дистә километрдан башлап дүртенче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 26,00 |
| 3. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны бишенче дистә километрдан башлап сигезенче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 22,00 |
| 4. | Сәфәр маршрутында тугызынчы дистә чакрымлык зонадан унөченче дистә чакрымлы зоналарга кадәр пассажирны алып барган һәр зонага өстәмә | 1 зона | 20,00 |
| 5. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны ундүртенче дистә километрдан башлап уналтынчы дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 15,00 |
| 6. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны унҗиденче дистә километрдан башлап егерменче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 13,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2023 № 816-63/т-2023
карарына 3 нче кушымта

Казан – Кизнер, Кизнер – Казан, Ижевск – Кизнер, Кизнер - Ижевск хәрәкәт маршрутлары буенча югары уңайлылыктагы вагоннарда «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртүгә тарифлар

| Т/с | Хезмәт күрсәтү классы | Чик дәрәҗә максималь тариф*, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | 1 сыйныф | 70 |
| 2. | 2 сыйныф | 50 |

* Әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән тарифларга өстәмә рәвештә кулланыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге